| ГЛАВА САКЛОВ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САКЛАУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛАГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
№ 9 05.11.2024

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Алга авылында 2025 нче елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 18.1 статьясы нигезендә. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Алга авылы элекке клубы бинасы каршындагы мәйданда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 15 нче ноябрь 2024 нчы ел 8:00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Саклаубаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан тыш, 2025 елда үзара салым акчаларын кертүгә, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) Алга торак пунктына урам яктырту челтәрләрен ясау.

2) автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);

3) Халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзеклзү (корыган агачларны кисү)

«ӘЙЕ» “ЮК".

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга. («Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында) һәм «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Саклаубаш, Өчөйле Саклау, Алга, Яңа Саклау авылларында урнашкан махсус мәгълүмат стендларында.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Саклаубаш авыл
җирлеге башлыгы Л.М.Габидуллина